ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 3.16 статья өстәргә:

«3.16 статья. **Транспорт чараларын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) урнаштырган өчен түләмәү**

Транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) урнаштырганга түләмәгән өчен –

ике мең биш йөз сум күләмендә административ штраф салына.

Искәрмә. Әлеге статьяда түләүле муниципаль парковка (парковка урыннары) дигәндә махсус билгеләнгән һәм кирәк булганда төзелгән һәм җиһазландырылган, шул исәптән җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлының өлеше булган һәм (яисә) юлның транспорт чарасы йөрү өлеше һәм (яисә) тротуар, юл кырые, эстакада яисә күпер янәшәсендәге урын булган йә эстакада астының яисә күпер астының, мәйданнарның һәм урам-юл челтәренең башка объектларының, биналарның яисә корылмаларның өлеше булган һәм вәкаләтле орган карары буенча

түләүле нигездә транспорт чараларын оешкан рәвештә куеп тору өчен билгеләнгән урыннан гыйбарәт территориянең төзекләндерү элементы (төзекләндерү объекты) дип аңларга кирәк.»;

2) 7.4 статьяда «3.2 – 3.6,» саннарыннан соң «3.16,» саннарын өстәргә;

3) 8.1 статьяның 14 өлешендә «3.7,» саннарыннан соң «3.16,» саннарын өстәргә;

4) 8 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 8.3 статья өстәргә:

«8.3 статья. **Беркетмә төземичә административ җәза билгеләү**

Әлеге Кодексның 3.16 статьясында каралган административ хокук бозу турындагы эш, бу административ хокук бозу фото- һәм киногә төшерү, видеога язу функцияләре булган автоматик режимда эшләүче махсус техник чаралар яисә фото- һәм киногә төшерү, видеога язу чаралары белән фиксацияләнгән очракта, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.6 статьясындагы 3 өлеше нигезендә беркетмә төземичә карала.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7), «3.2 – 3.7,» саннарыннан соң «3.16,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән сон 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 4 марты
№ 7-ТРЗ